# Нәби Дәүли (1910-1989 ел) күренекле шагыйрь



Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) 1910 елның 1 июнендә элекке Казан губернасы Спас өязе (хәзерге Татарстан АССРның Әлки районы) Мәүләшә (Иске Камка) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Дүрт яшендә чакта аның әтисе, бераздан әнисе үлеп китә, Нәбиулла ятим кала. 1921 елда ул Царицын (хәзерге Волгоград) шәһәрендә балалар колониясенә эләгә. Шунда җидееллык белем ала, ФЗӨдә укый, беренче әдәби әсәрләрен бастыра. Озакламый Донбасс ягына китеп, «Пролетар» исемле татар газетасы редакциясендә эшли.

1931–1933 елларда ул Винница шәһәрендәге хәрби мәктәптә укый, Ерак Көнчыгышта чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә.

1935 елда Нәби Дәүли Казанга килеп матбугат органнарында эшли, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. 1939 елда ул СССР Язучылар союзына член итеп алына. Нәби Дәүли Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, әмма 1941 елның августында Орша шәһәре тирәсендә барган авыр сугышларның берсендә чолганышта калып, ул фашистлар кулына әсир төшә, 1942 елның яз башында бүтән әсирләр белән бергә Германиягә озатыла. 1945 елның апрелендә ул берничә иптәше белән лагерьдан кача, Совет Армиясенә кушыла һәм сугышны фронтта тәмамлый. 1945-1956 елларда ул Казанда художник-бизәүче булып эшли. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби иҗат эшеннән аерылмады.



# Нәби Дәүли

## күренекле шагыйрь



**1910 – 1989**

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, әмма 1941 елның августында Орша шәһәре тирәсендә барган авыр сугышларның берсендә чолганышта калып, ул фашистлар кулына әсир төшә, 1942 елның яз башында бүтән әсирләр белән бергә Германиягә озатыла. 1945 елның апрелендә ул берничә иптәше белән лагерьдан кача, Совет Армиясенә кушыла һәм сугышны фронтта тәмамлый. 12 ел язучыга үзенең әсәрләрен бастырырга ирек бирмиләр һәм ул 1945-1956 елларда Казанда кара эшче, каравылчы, рәссам-бизәүче булып эшли. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби иҗат эшеннән аерылмый. 1957 елда аның «Үлем белән яшәү арасында» исемле романы дөнья күрә, бик тиз арада танылып китә.

Базарлы Матак авылы гимназиясе Нәби Дәүли исемен йөртә.

# Әлки районында Нәби Дәүли исемендәге татар гимназиясе













Нәби Дәүли ясаган картиналар

# *Яшәү белән үлем арасында...*






# Авыр истәлек

Нәби Дәүли 23 елдан соң, шәһәрне азат итүнең 20 еллыгына (1964 ел) чакырыла.

Ул болай яза: "...Мин кичә элеккеге лагерь булган урыннарны карап йөргән чакта, тәбәнәк кенә таш биналар янына килеп туктаган идем. ... Бу таш биналар артында безнең лагерь каберлеге иде. Биредә берсеннән-берсе тирән, берсеннән-берсе зур өч баз бар иде. Лагерьда минем беренче иртәм шул урында башланды. Мин ул чакта биредә иң элек үземнең каберемне күрдем, тимер чыбыклы койма аркылы таң атканын күрдем. Һәм шуңа күрә китабымның исемен дә **"Яшәү белән үлем арасында"** дип атадым.



# “Җимерелгән бастион”

Н.Дәүли ясаган рәсемнәр





“ **Яшь кеше!** Әгәр син, иртә белән тыныч йокыдан уянгач, тәрәзә төбендә ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрсәң, әгәр син шул иртәдә өй каршындагы тирәкләрдә кошларның сайравын ишетсәң, бел – бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калган солдатларның, фашизм тоткынлыгында һәлак булган ватандашларыңның ялкынлы тормышы бар. “

Нәби Дәүли